ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТМУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАНРЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬРАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

_06.04.2021___ Мөслим №__151___

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан халыкка хезмәт күрсәтү тарифларын раслау турында**

«Адреслылык принцибын саклау һәм мохтаҗлык критерийларын куллану бурычыннан чыгып социаль яклау чараларын бирүне исәпкә алу һәм камилләштерү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 29 декабрендәге 3338-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Мөслим муниципаль районы Уставына таянып, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны расларга (1 нче кушымта).
2. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлегенә (И.Р. Җаббаровка) ведомство карамагындагы учреждениеләрдә расланган тарифларны куллануны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны «Авыл утлары» газетасында бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-мәдәни үсеш буенча урынбасары М. Р. Бәдретдиновага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Р.Т. Демидов**

Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитетының
«____» ___________________
____ номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар

| № т/б | Хезмәт төре атамасы | Физик затлар өчен хезмәт күрсәтү бәясе | | Ташламалы категорияләр өчен хезмәт күрсәтү бәясе | | | | Юридик затлар өчен хезмәт күрсәтү бәясе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Зурлар | Балалар | Күп балалы гаиләләр, аз тәэмин ителгән гаиләләр | Ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар | Пенсионерлар, инвалидлар | Бөек Ватан сугышы һәм Хезмәт ветераннары | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| 1 | УСЗ<br>Тренажер залы<br>Мөслим авылы<br>Пушкин ур., 92 а | 1 кешегә аена 1000 сум | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 1 кешегә аена 1000 сум |
| 2 | «Тамчы» ЙБ<br>Йөзү<br>Мөслим авылы<br>Ф. Рәшитов ур., 60 | 1 сәгате 100 сум<br>1 кешегә аена 1000 сум | 1 сәгате 50 сум<br>Аена<br>1 балага 500 сум | 0 | 0 | 0 | 0 | 1 кешегә аена 1000 сум |
| 3 | Чаңгы базасы<br>Прокатка чаңгы<br>Мөслим авылы<br>Яр буе ур., 27 | 1 сәгате 100 сум | 1 сәгате 50 сум | 0 | 0 | 0 | 0 | 1 сәгате 100 сум |